Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль район Советы
КАРАРЫ

**2024 ел 02 апрелендәге** **№ 197**

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында» Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының 2016 елның 18 апрелендәге 36 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында» Федераль законның 12 статьясына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына, «муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында "2023 елның 2 ноябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында" 2023елның 12 декабрендәге 594-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында» 2016 елның 18 апрелендәге 36 номерлы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 бүлекнең 13 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Муниципаль хезмәткәргә класслы чин бирү турындагы карар, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясындагы 13 өлешендә күрсәтелгән очраклардан тыш, җирле үзидарәнең органына яисә вазыйфаи затына кирәкле барлык документлар белән класслы чин бирү турында тапшыру кертелгән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.».

1.2. 8 бүлекнең 29 пунктындагы 11 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. муниципаль хезмәткә кергәндә һәм муниципаль хезмәткәрләргә узган вакытта граждан тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрне тикшерүне оештыру һәм үткәрү;».

1.3. 4 бүлекнең 15 пунктындагы 11 пунктчасының 8 абзацында «белешмәләр» сүзеннән соң «(анкетадагы белешмәләрдән тыш)» сүзләрен өстәргә;

1.4. 3 бүлекнең 12 пунктындагы 8 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм (яисә) аны үткән чорда ялган документлар һәм (яисә) аны бозган өчен муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә тоткарлык ясый торган чикләүләрнең, тыюларның һәм таләпләрнең үтәлүен раслый торган, йә документларны һәм (яисә) белешмәләрне тапшырмау, алар муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә тоткарлык ясый торган чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү турында таныклый;

1.5. 3 бүлекнең 11 пунктының 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 12 пунктча өстәргә:

«12) яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясында каралган анкетада булган белешмәләрнең мәгълүм үзгәрешләре турында язма рәвештә хәбәр итәргә, аларның үзгәрүе яллаучы (эш бирүче) вәкиле карары буенча булган белешмәләрдән тыш (алга таба - анкетадагы белешмәләр).».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башлыгы урынбасары И.Т. Гыйниятовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Советы рәисе Н.А.Вазыйхов